ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь 2025 ел № 9165

Башкарма комитетның 2025 елның 16 октябрендәге 8373 номерлы Карары белән расланган Күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча лизинг түләүләрен түләү буенча чыгымнарны (чыгымнар өлешен) финанс белән тәэмин итү (кайтару) максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2025 елның 16 октябрендә 8373 номерлы Карары белән раслаган Күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча лизинг түләүләрен түләү буенча чыгымнарны (чыгымнар өлешен) финанс белән тәэмин итү (кайтару) максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 пунктта «әлеге Тәртип рәсми бастырып чыгарылган датага» сүзләрен «03.10.2025» цифрларына алмаштырырга;

2) Күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча лизинг түләүләрен түләү буенча чыгымнарны (чыгымнар өлешен) финанс белән тәэмин итү (кайтару) максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү өчен юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә «әлеге Тәртип рәсми бастырып чыгарылган датага» сүзләрен «03.10.2025» цифрларына алмаштырырга;

3) Күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча лизинг түләүләрен түләү буенча чыгымнарны (чыгымнар өлешен) финанс белән тәэмин итү (кайтару) максатында заявкалар соратып алуда катнашуга заявкада «әлеге Тәртип рәсми бастырып чыгарылган датага» сүзләрен «03.10.2025» цифрларына алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов